ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 октябрь 2020 ел № 5119

Рекультивация проектын капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә проект документлары составында әзерләү очракларыннан һәм федераль законнар белән билгеләнгәнчә, җирләрне рекультивацияләү проекты расланганчы ул дәүләт экспертизасы үтәргә тиешле очраклардан тыш, җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезләмә, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Рекультивация проектын капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә проект документлары составында әзерләү очракларыннан һәм федераль законнар белән билгеләнгәнчә, җирләрне рекультивацияләү проекты расланганчы ул дәүләт экспертизасы үтәргә тиешле очраклардан тыш, җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны тәэмин итәргә, аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында (www.nabchelny.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 7 октябрендәге
5119 номерлы карарына
кушымта

Рекультивация проектын капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә проект документлары составында әзерләү очракларыннан һәм федераль законнар белән билгеләнгәнчә, җирләрне рекультивацияләү проекты расланганчы ул дәүләт экспертизасы үтәргә тиешле очраклардан тыш, җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – регламент) рекультивация проектын капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә проект документлары составында әзерләү очракларыннан һәм федераль законнар белән билгеләнгәнчә, җирләрне рекультивацияләү проекты расланганчы ул дәүләт экспертизасы үтәргә тиешле очраклардан тыш, җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы – «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – АТИИ).

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризалар кабул итүне Башкарма комитет гамәлгә ашыра.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 282 кабинет.

АТИИның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 255 кабинет.

Башкарма комитетның эш графигы:
дүшәмбе – җомга: 8:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр.
шимбә, якшәмбе: ял көннәре.
Төшке аш вакыты: 12:00 дән 13:00 сәгатькә кадәр.
АТИИның белешмә телефоны: (8552) 30-56-51.
Керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы: (http://nabchelny.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында, шулай ук АТИИның урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат түбәндәге юл белән алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет кабинетларында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) муниципаль хезмәт турында мәгълүматны үз эченә ала.

2) «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты (http://nabchelny.ru) аша;

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта аша электрон рәвештә: mky_ati@mail.ru.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат АТИИ белгече тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет кабинетларындагы мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе (Российская газета, № 237, 25.12.1993);

Россия Федерациясенең 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Җир кодексы (алга таба – РФ Җир кодексы) (РФ законнары җыентыгы, 29.10.2001, № 44, ст. 4147);

Россия Федерациясе Урман кодексы (Российская газета, № 277, 08.12.2006, Россия Федерациясе законнары җыентыгы, №50, ст. 5278, 11.12.2006, Парламентская газета, № 209, 14.12.2006);

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы) (РФ законнары җыентыгы, 03.01.2005, № 1 (1 бүлек), ст. 16);

Россия Федерациясенең 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Граждан кодексы (беренче бүлек) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 05.12.1994, № 32, ст. 3301; Российская газета, 08.12.1994, № 238-239);

Россия Федерациясенең 1996 елның 26 гыйнварындагы 14-ФЗ номерлы Граждан кодексы (икенче бүлек) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.01.1996, № 5, ст. 410; Российская газета, 06.02.1996, № 23; 07.02.1996, № 24; 08.02.1996, № 25; 1002.1996, № 27);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 06.10.2003, № 40, ст. 3822);

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 7-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 14.01.2002, №2, ст. 133);

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 05.04.1999, №14, ст. 1650);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (Российская газета, 05.05.2006, № 95; Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 08.05.2006, № 19, ст. 2060; Парламентская газета, 11.05.2006, № 70-71);

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 30.07.2007, № 31, ст. 4017; Парламентская газета, 09.08.2007, № 99-101; Российская газета, 01.08.2007, № 165);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирләрне рекультивацияләүне һәм консервацияләүне үткәрү турында» 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, № 29, ст. 4441, 16.07.2018);

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, № 155-156, 03.08.2004);

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турында» 2013 елның 30 маендагы 25/14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 31 октябрендәге 27/15 номерлы карары (алга таба –Шәһәр Советы 27/15 номерлы карары);

Башкарма комитетның 2020 елның 25 февралендәге 101-Р номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр);

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр файдаланыла:

рекультивация – җирләрне максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану нигезендә файдалану өчен яраклы торышка китерү, шулай ук туфрак пычрану нәтиҗәләрен бетерү, туфракның уңдырышлы катламын торгызу һәм саклаучы урман утыртмалары булдыру юлы белән җирләрнең деградацияләнүен кисәтү һәм (яки) аларның уңдырышлылыгын торгызу буенча чаралар;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр округында булдырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 пункт). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 нче кушымта).

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандарт таләпләренең эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Рекультивация проектын капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә проект документлары составында әзерләү очракларыннан һәм федераль законнар белән билгеләнгәнчә, җирләрне рекультивацияләү проекты расланганчы ул дәүләт экспертизасы үтәргә тиешле очраклардан тыш, җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү | РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы карары |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның исеме | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән АТИИ | Шәһәр Уставның<br>41 статьясы<br>Шәһәр Советының<br>27/15 номерлы карары |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү турында белдерү кәгазе<br>Җирләрне рекультивацияләү проектын килештерүдән баш тарту турында белдерү кәгазе | РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы карары |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Муниципаль хезмәт гариза биргән көнне дә кертеп, 20 эш көне эчендә күрсәтелә. | РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы карары |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | 1) Гариза (1 нче кушымта);<br>2) Шәхесне раслаучы документлар;<br>3) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (гариза бирүче исеменнән вәкил эш иткән очракта);<br>4) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирләрне рекультивацияләүне һәм консервацияләүне үткәрү турында» 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы карары нигезендә әзерләнгән җирләрне рекультивацияләү проекты (төп нөсхә 2 данәдән дә ким түгел һәм электрон документлар рәвешендә (docx һәм pdf форматында) 1 данә).<br>Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Башкарма комитетта алырга | РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч язуы нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аша.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацион электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Муниципаль хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алыналар:<br>1) Рекультивация проектында каралган җир участогына Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә.<br>2) Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан (гариза бирүче шәхси эшмәкәрләр өчен) яки Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан (гариза бирүче юридик затлар өчен).<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүче әлеге регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны мөстәкыйль тапшырырга хокуклы.<br>Гариза бирүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документлар тапшырылмау гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килештерү (муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла) таләп | Килештерү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| ителә торган дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Документлар тиешле булмаган зат тарафыннан бирелү;<br>2) Тапшырылган документлар әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү;<br>3) гаризада һәм гаризага теркәлә торган документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлатмый торган җитди кимчелекләр булу;<br>4) Документларны тиешле булмаган органга тапшыру | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) Гариза бирүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган яисә бирелгән гаризада һәм (яисә) документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат булу;<br>2) Әгәр тиешле документны гариза бирүче үз инициативасы белән бирмәгән булса, дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, яисә дәүләт хакимиятенең ведомство буйсынуындагы органы, яисә җирле үзидарә органы тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яисә) мәгълүмат булмауны дәлилләүче ведомствоара запрос;<br>3) Рекультивация проектында каралган чаралар җирләрнең максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану нигезендә алардан файдалану өчен җирләрне яраклы торышка кадәр торгызуны тәэмин итмиләр, шулай ук җирләр сыйфатының халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендә әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативларына һәм Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүен тәэмин итмиләр, ә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең уңдырышлылыгын тәэмин итү өлкәсендә шулай ук авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә карата нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килүне тәэмин итмиләр. | РФ Хөкүмәтенең 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | 4) Рекультивация проектында каралган рекультивацияләнә торган җирләрнең һәм җир участокларының мәйданы рекультивация үткәрү таләп ителә торган җирләр һәм җир участоклары мәйданына туры килми;<br>5) Җирләрне рекультивацияләү проектының «Аңлатма язуы» бүлегендә рекультивацияләнә торган җирләр һәм җир участоклары турында дөрес булмаган мәгълүматлар булу;<br>6) Җирләрне рекультивацияләгәннән соң аларның максатчан билгеләнеше һәм рөхсәт ителгән файдалану белән килешмәү, әгәр андый максатчан билгеләнеш һәм рөхсәт ителгән файдалану рекультивация үткәрүгә кадәр билгеләнгән максатчан билгеләнеш һәм рөхсәт ителгән файдалануга туры килмәсә. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, муниципаль хезмәттән файдалануга гариза бирү – 15 минуттан артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел. | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнне электрон рәвештә кергән запрос ялдан (бәйрәмнән) соңгы эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар тутыру өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Инвалидларга муниципаль хезмәттән файдалану урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәтләнү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедия мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны да истә тотып урнаштырыла. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлек итүләр саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтүне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацон технологияләрне файдаланып | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>документлар кабул итү һәм тапшыру бинасының җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәренең мәгълүмат ресурсларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә документлар биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәвенә) шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтә торган вазыйфаи зат белән гариза бирүченең бер тапкыр хезмәттәшлек итүе күздә тотыла.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү аша яки Татарстан Республикасының Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә алырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон рәвештә бирү законда каралган булса, ул очракта гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi. tatar.ru/) аша яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http:// www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запросларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) Рекультивация проектын капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә проект документлары составында әзерләү очракларыннан һәм федераль законнар белән билгеләнгәнчә, җирләрне рекультивацияләү проекты расланганчы ул дәүләт экспертизасы үтәргә тиешле очраклардан тыш, җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү мәсьәләләре буенча комиссия утырышы үткәрү (алга таба – комиссия);

5) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

6) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен Башкарма комитетка, АТИИга шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

АТИИ белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалану өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат аша яки КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма рәвештә гариза бирә һәм документларны әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон рәвештәге гариза электрон почта яки Интернет-кабул итү аша эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен ачыклау;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү (ышаныч язуы белән эш иткән очракта);

әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерү;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бозып язулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм килешенмәгән башка төзәтүләр булмау).

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

гариза бирүчегә документларны кабул итү датасы, бирелгән керү номеры турында билге куеп, документ тапшыру;

гаризаны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә (алга таба – Башкарма комитет Җитәкчесе) җибәрү.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризаларны кабул итүче белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган сәбәпләрнең эчтәлеген аңлатып, документларын кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

гариза һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Башкарма комитет Җитәкчесенә карап тикшерү өчен җибәрелгән гариза һәм документлар яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны карап тикшерә һәм гаризаны АТИИга җибәрә, АТИИ башлыгы башкаручыны билгели

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара запросларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.4.1. АТИИ белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә Бердәм дәүләт күчемсез милеккә хокуклар һәм аның белән килешүләр реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык мәгълүматларны үз эченә алган) бирү турында запрос җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон рәвештә җибәрелгән запрос.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрос нигезендә, соралган документларны (мәгълүматны) бирә яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында белдерү кәгазе (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар документ һәм мәгълүмат бирүче орган яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: АТИИ белгеченә җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5. Комиссиядә карап тикшерү өчен документлар пакетын әзерләү

3.5.1. АТИИ белгече гамәлгә ашыра:

тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөреслеккә туры килүен тикшерү;

исәп делосын рәсмиләштерү (барлык документларны аерым папкага туплау);

исәп делосын комиссия каравына җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар запросларга җаваплар кергән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: комиссиягә җибәрелгән исәп делосы.

3.6. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Комиссия утырышында җирләрне рекультивацияләү проекты карап тикшерелә һәм җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү турында яки килештерүдән баш тарту турында карар (алга таба – карар) кабул ителә. Комиссия секретаре имзаланган карарны АТИИ белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү турындагы гариза комиссия секретарена кергән көннән башлап 7 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү турында яки килештерүдән баш тарту турында АТИИ белгеченә җибәрелгән карар.

3.6.2. АТИИ белгече комиссия карары нигезендә җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү турында белдерү кәгазе проектын әзерләүне яки җирләрне рекультивацияләү проектын килештерүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын әзерләүне гамәлгә ашыра һәм аны имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән килештерү турында белдерү кәгазе (баш тарту турында белдерү кәгазе).

3.6.3. Башкарма комитет Җитәкчесе рекультивацияләү проектын килештерү турында белдерү кәгазе проектын яки җирләрне рекультивацияләү проектын килештерүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын имзалый һәм теркәү өчен АТИИ белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рекультивацияләү проектын килештерү турында белдерү кәгазе проектын яки җирләрне рекультивацияләү проектын килештерүдән баш тарту турында имзаланган һәм теркәү өчен АТИИ белгеченә җибәрелгән белдерү кәгазе.

3.7. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.7.1. АТИИ белгече килештерү турында белдерү кәгазен (баш тарту турында белдерү кәгазен) терки һәм гариза бирүчегә тапшыра яисә почта аша җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

гариза бирүче шәхсән килгән очракта – 15 минут эчендә;

җавап почта белән җибәрелгән очракта - алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер көн эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү турында бирелгән белдерү кәгазе (баш тарту турында белдерү кәгазе).

3.8. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү.

3.8.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.8.2. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.3. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮдән документлар кергәндә, процедуралар әлеге регламентның 3.3 – 3.6 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.9. Техник хаталарны төзәтү.

3.9.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (2 нче кушымта);

гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

юридик көчкә ия һәм техник хата булуны таныклаучы документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып), яисә бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк аша тапшырыла.

3.9.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны АТИИга тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен АТИИ белгеченә җибәрелгән гариза.

3.9.3. АТИИ белгече документларны карап тикшерә һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатында әлеге регламентның 3.6 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм техник хата булган документның төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алгач, шәхсән имза куйдырып, төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки почта аша (электрон почта аша) гариза бирүченең адресына, техник хата булган документның төп нөсхәсен АТИИга тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан яки җибәрелгән хата турында теләсә кайсы кызыксынган зат тарафыннан гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, Башкарма комитет вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш кәгазьләрен алып баруга карата билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә эш итүләрне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатында Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеге Башкарма комитетның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи инструкцияләр нигезендә билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында каралмавы өчен җаваплы.

АТИИ башлыгы әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул иткән (гамәлгә ашырган) карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5 Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең эш итүләренә (эш итмәвенә) судка кадәр тәртиптә Башкарма комитетка шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату.

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http://www.gosuslugi.ru/) рәсми сайтыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш.

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәвенә) шикаять бирелә торган хезмәт күрсәтүче органның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрстүче Башкарма комитетның, муниципаль хезмәт күрстүче Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәве) турында мәгълүмат;

4) муниципаль хезмәт күрстүче Башкарма комитетның, муниципаль хезмәт күрстүче Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәренең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

5.6. Шикаять аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча комиссия рәисе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре

муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, Башкарма комитетның шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи заты булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева

Регламентка 1 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесе
______________________________

______________________________
______________________________
______________________________
(алга таба – гариза бирүче)
(юридик затлар өчен - тулы исеме, оештыру-хокукый формасы, дәүләт теркәве турында мәгълүматлар; физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары)

Рекультивация проектын капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә проект документлары составында әзерләү очракларыннан һәм федераль законнар белән билгеләнгәнчә, җирләрне рекультивацияләү проекты расланганчы ул дәүләт экспертизасы үтәргә тиешле очраклардан тыш, җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү турында

ГАРИЗА

______________________________________________ урнашкан,
(урнашу урыны)

мәйданы ________ кв.м булган җирләрне рекультивацияләү проектын килештерүне сорыйм.

______________________________________________ бирелгән
(кемгә һәм нинди хокукта)

җир участогының кадастр номеры (булган очракта) ______________________

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:
1. ______________________________ ______ биттә _______ нөсхәдә.
2. ______________________________ ______ биттә _______ нөсхәдә.
3. ______________________________ ______ биттә _______ нөсхәдә.

Документларны алу ысулы:
- шәхсән;
- гаризада күрсәтелгән адрес буенча почта аша;
- электрон документлар рәвешендә гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына.

Дата ________________ 20___ ел          ______________________
МУ (мөһер булган очракта)          (имза)

Регламентка 2 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесе
________________________________

________________________________
________________________________
________________________________
(алга таба – гариза бирүче)
(юридик затлар өчен - тулы исеме, оештыру-хокукый формасы, дәүләт теркәве турында мәгълүматлар; физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары)

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

________________________________________________
(хезмәтнең исеме)
муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган: ________________________________________
________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: ________________________________
____________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail: ____________________ адресына җибәрү юлы белән;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне:
____________________________________________________.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның сканерланган күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала. Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: ________________.

______________ ________________ (___________________________________ )

(дата) (имза) (Ф. И. А.и.)

Кушымта
(белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм
аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның
реквизитлары

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | Farid.Salahov@tatar.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» МКУ башлыгы | 30-56-51 | Almaz.Hammatov@tatar.ru |
| «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы административ-техник инспекция идарәсе» МКУ белгече | 30-57-77 | mky_ati@mail.ru |